**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ ЕГОРЬЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

422621 д.Каипы
ул. Центральная д.50
тел: 8-(84378)-3-36-19
факс: 8-(84378)-3-36-19
Egor.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**УРТА ЕГОРЬЕВО АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422621 а.Каипы
Центральная урамы, 50 нчы йорт,
тел: 8-(84378)-3-36-19
факс: 8-(84378)-3-36-19
Egor.La@tatar.ru

**2023елның «20» ноябре** **48 номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлеге «муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 12 декабрендәге 41 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлеге карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Территорияләрнең комплексны үсешен тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә, кушымта нигезендә, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка чыгарылган)көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Егорьево**
**авыл җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы** **И.Б.Зарипов**

*Татарстан Республикасы*
*Лаеш муниципаль районы*
*Егорьево авыл җирлеге Советының*
*2023 елның « 20 » ноябрендәге*
*48 номерлы карарына*
*кушымта*

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлеге «муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында»2018 елның 12 декабрендәге 41 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлеге карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

**12 статьяның 3 абзацына түбәндәге сүзләрне өстәргә:**

-территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә җирлекнең генераль планына үзгәрешләр әзерләнгән очракта, иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин.